| | | |
|---|---|---|
| **ГЛАВА РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ БАШЛЫГЫ** |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

10.10.2018 Балык Бистәсе штп. №11рг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2016 елның 31 маендагы 06рг номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында хезмәт тикшерүләре оештыру турындагы Инструкциягә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга ярашлы итү максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 193 маддәсенә туры китереп:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2016 елның 31 маендагы 06рг номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында хезмәт тикшерүләре оештыру турындагы Инструкциягә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

31 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дисциплинар җәза, чикләүләр һәм тыюларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җәзадан гайре, гаеп эш кылынган көннән алты айдан соң кулланыла алмый, ә ревизия, финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү яисә аудитор тикшерүе нәтиҗәләре буенча – аны кылган көннән ике елдан соң.Чикләүләр һәм тыюларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җәза гаеп эш кылынган көннән өч елдан соң кулланыла алмый. Җинаять эше буенча эш алып бару вакыты күрсәтелгән срокларга кертелми.».

2.Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыныңhttp://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»ында урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Р.Д.Исмәгыйлевкә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р.Таҗетдинов